ШИМБӘ
17 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 39 (5839)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат кузәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Колхоз тормышының законы

Колхозчы ударникларның II нче Бөтенсоюз съезды булып үтүгә нак биш ел тулды. 1935 нче елның 17 нче февралендә авыл хуҗалыгы артеленең Уставы, колхоз тормышының төп законы расланган көн. Бу көнне колхозчы крестьяннәр генә түгел, бәлки бөтен ил, барлык хезмәт ияләре мәшһүр дата итеп билгеләп үтәләр.

Авыл хуҗалыгы артеленең Уставы, — ул бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның даһи иҗады. Данлыклы хәзерге заман эпохасының бу бөек документының барлыкка килүе иптәш Сталин исеме белән нык бәйләнгән. Авыл хуҗалыгы артеленең Уставы турыдан-туры иптәш Сталин катнашуы белән, турыдан-туры аның җитәкчелегендә иҗад ителде. Авыл хуҗалыгы артеленең Уставы коллективлашу хәрәкәтендә, колхоз төзелеше тарихында зур урын тотты һәм тота. Күп миллионлы крестьяннәр, Уставта әйтелгәнчә, **„Колхоз юлы, социализм юлы—хезмәт иясе крестьяннәр өчен бердәнбер дөрес юл“** белән киттеләр, колхозларны үстерүдә һәм ныгытуда искиткеч уңышларга ирештеләр. Колхоз Уставының бөек оештыру көче әнә шунда.

Артель Уставы, колхоз төзелешенең артель формасы хәзерге чор өчен иң дөрес, иң яраклы форма булып тора. Чөнки артельнең Сталин Уставы колхозларда җәмагат интересларын шәхси интереслар белән кушуның, шәхси интересларны җәмагат интересларына яраштыруның бердәнбер дөрес принципларын үз эченә ала.

Артельнең Сталин Уставын кабул иткәннән соң үткән биш ел социалистик авыл хуҗалыгының гигант адымнар белән, триумфаль марш белән алга китү еллары булды. Колхозчы ударникларның II нче съезды такдиме буенча Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсен ачу оештырылды һәм ул, күргәзмә, колхоз төзелешендә яулап алынган бөек уңышларны, бай тәҗрибәләрне бергә туплау, уртаклашу һәм киләчәк җиңүләр өчен тәҗрибә алу мәктәбе булып әверелде.

Колхоз төзелеше өчен артель Уставының һәрбер бүлеге, һәрбер статьясе әһәмиятле. Аларның барсы да колхозларны большевистик итүгә, колхозчыларны таза тормышлы итүгә юнәлдерелгән. Ничә йөз еллар буена җир өчен, бер телем икмәк өчен аһ-зар җылаган элеккеге ярлы крестьяннәр, җирсезлектән җәфаланган урта хәлләләр Октябрь революциясе нәтиҗәсендә алган җирләрен Сталин Уставы буенча түләүсез һәм сроксыз файдалануга алдылар. Гомуми халык милке булган **җир артельгә мәңгелеккә беркетелде!** Элеккеге ызаннар, межалар юкка чыгарылды, катлаулы машиналар белән эшкәртелә торган, яхшы ашламалар белән тукландырыла торган җирләр, хезмәтне сөеп эшли торган колхозчы крестьяннәр карамагындагы социалистик кырлар илнең чәчәк ата торган бакчасына әверелделәр.

Сталин Уставын кабул иткәннән соң колхозчылар үзләренә гаять зур бурычлар алдылар. Ул бурычларның иң әһәмиятлеләре: иген уңышын күтәрү белән, терлекчелекне үстерү белән үз артелен ныгыту, намус белән эшләү, колхоз доходын хезмәт буенча бүлү, җәмагат милкен, тракторларны һәм башка машиналарны саклау, колхоз байлыгын әрәм-шәрәм итмәү, атны яхшы итеп карау һәм **эшче-крестьян дәүләтенең заданиеләрен вактында һәм намус белән үтәү.** Артель хуҗалыгындагы эшләр әнә шушы төп бурычларны үтәү өчен көрәш билгесе астында барды, колхозлар хуҗалык һәм оешу ягыннан ныгыдылар һәм ныгыйлар. Гүзәл кадрлар җитеште. Авыль хуҗалыгы танымаслык булып үзгәрде, артельнең җәмагат хуҗалыгы—колхоз строеның төп нигезе һичбер вакыт какшамаслык булып үсте, ныгыды. Колхозчы крестьяннәр җәмагат милкен саклау, аны баету өчен көрәштә социалистик рухта тәрбия алдылар, җәмагат милке ул барыннан да кыйммәтлерәк, ул изге милек дигән караш нык урнашты.

Ленин—Сталин партиясе һәм Совет хөкүмәте социалистик авыл хуҗалыгын алга җибәрү, үстерү турында өзлексез рәвештә кайгыртучанлык күрсәтәләр. Колхозларга гаят зур ярдәм күрсәтәләр.

Бу ярдәмнең никадәр зур булуын орденлы Татарстан мисалендә генә дә бик ачык күрәбез. Хәзер Татарстанда 103 машина-трактор станциясе бар. Татарстан МТС ларында гына да 5.436 трактор һәм 3.000 комбайн эшли. Колхозлар башка тармаклар буенча да дәүләттән бик күп ярдәм алдылар һәм алалар. Ләкин шуларның барсына да карамастан, Татарстан колхозлары иген уңышы алуда соңгы ике елда планны үти алмадылар. 1939 нчы елның авыл хуҗалыгы эшләре планын үтәү тирән өзеклекләр белән барды, иген уңышы түбән булды. Бу хәл колхоз строеның нигезендә булган хисапсыз күп мөмкинлекләрдән кирәгенчә файдалана белмәү, югары иген уңышы өчен көрәшкә колхозчылар массасын җитәрлек туплый алмау нәтиҗәсендә килеп чыкты.

Партия, совет оешмаларының һәм барлык колхозчыларның бурычлары—1940 нчы елны иген уңышын кискен рәвештә күтәрү елы, авыл хуҗалыгы эшләрен башкаруда Татарстанның арттагылыгын бөтенләй бетерү елы итүдән гыйбарәт. Моның өчен язгы чәчүгә хәзерлекне һәм чәчүне большевистик оешканлык белән үткәрергә кирәк.

Колхозлар үз алларында торган бурычларны төгәл һәм үз вактында үтәсеннәр өчен авыл хуҗалыгы Уставының тормышка ашырылуын әледән-әле тикшереп торырга, аны бозуларга һич тә юл куймаска кирәк.

Устав—ул закон. Уставтан читкә чыкмаганда, аны намус белән тулы үтәгәндә һәрбер колхоз зур уңышларга ирешәчәк, ул колхозчыларны зур җиңүләргә алып киләчәк. Сталин Уставы колхозларны чын большевистик итү, ә колхозчыларны таза тормышлы итү, социалистик рухта тәрбияләү өчен иң көчле корал булып тора. Уставның бишьеллыгы барлык колхозчыларны 1940 нчы елда бөек эшләр планын үтәү тирәсенә туплау өчен көчле этәргеч булып хезмәт итәргә тиеш. Авыл хуҗалыгы артеленең Уставында, заманыбызның бу бөек документында гәүдәләнгән идеяләр социалистик авыл хуҗалыгының тагын да матуррак, тагын да гүзәлрәк булып чәчәк атуына алып барачак.

БОЛГАРИЯ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ ОТСТАВКАГА ЧЫГУЫ

СОФИЯ, 15 февраль. (ТАСС). Кичә иртән 11 сәгаттә Борис патша баш министр Киоссейвановны кабул итте. Киоссейванов кабинетның отставкага чыгуын белдерде. Патша, кабинетның отставкага чыгуын кабул итте.

СОФИЯ, 15 февраль. (ТАСС). Болгария телеграф агентлыгының хәбәр итүенә караганда, патша яңа кабинет төзүне элекке мәгариф министре Богдан Филовка тапшырган.

***

Богдан Филов 1883 нче елны туган. Ул—София университетының археология һәм тарих профессоры. Киоссейвановның соңгы ике кабинетында мәгариф министре булган иде.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

15 нче февральдә Карелия бугазында безнең гаскәрләрнең уңышлы хәрәкәтләре дәвам итте. Дошман, коралларын һәм сугыш кирәк-яракларын ташлап, зур югалтуларга дучар булып, тылга кача. Безнең гаскәрләр **Кямяря** станциясенә килеп җиттеләр.

15 нче февральдә безнең гаскәрләр дошманның ныгытылган 53 оборона пунктын алдылар. Шуларның 21 е тимер-бетоннан ясалган артиллерия корылмалары.

Фронтның башка участкыларында 15 нче февральдә разведчикларның эзләнүләре һәм күп кенә районнарда пехота частьләренең бәрелешләре булды.

Безнең авиация дошман гаскәрләренә һәм аның сугыш объектларына уңышлы хәрәкәтләр ясады. Һавада булган сугышта дошманның 6 самолеты бәреп төшерелде.

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 15 февраль. Гавас агентлыгының көнбатыш фронттагы хәл турында 14 нче февральдәге белдерүендә болай диелә: „20 градуска җиткән салкыннарга да карамастан, үткән тәүлек эчендә фронтта берничә эпизод булганлыкны әйтергә мөмкин. Үткән төндә патрульләрнең гадәттәге хәрәкәтләреннән тыш Битштан төньяктарак булган районда кӧтелмәгәндә Германия артиллериясеннән ату булды. Икенче яктан, Германия командованиесе Мозельдән көнчыгыштарак булган районда көн саен һөҗүмнәр ясап тора башлады.

Һава шартларының уңайлы булуыннан файдаланып, берничә разведка самолеты, истребительләр белән берлектә, очышлар ясады. Немецләр Франциянең көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш районнарына өч разведка самолеты җибәрделәр“.

Кичә кич Парижда иглан ителгән рәсми белдерүдә болай диелә: „Саардан көнбатыштарак дошманның һөҗүме аның җиңелүе белән бетте. Германиянең сәүдә карабы тотылып, Франция портына китерелде“. Иртәнге белдерүдә болай диелгән: „Кичә кич Саардан көнчыгыштарак алгы частьләрнең җирле хәрәкәтләре күренде“.

БЕРЛИН, 15 февраль. Германия армиясенең верховный командованиесе хәбәр итә: „Саарбрюкеннан көньяктарак чик буе районында разведка хәрәкәте вактында берничә француз солдаты плен алынды. 14 нче февраль көне Германиянең хәрби диңгез көчләре өчен, беренче чиратта Германиянең су асты көймәләре өчен аеруча уңышлы үтте. Бу көнне Германиянең су асты көймәләре дошманның барлыгы 58 мең тонна авырлыктагы пароходларын батырдылар“.

ОСЛО, 14 февраль. Данияннең Төньяк диңгездә батырылган „Частине Меркс“ пароходы экипажының 30 кешесен Норвегия пароходының коткарганлыгы хәбәр ителә. „Частине Меркс“ пароходы фосфат ашламалар төяп Даниягә бара иде.

ЛОНДОН, 14 февраль. Рейтер агентлыгы бүген Шотландиянең төньяк-көнчыгыш яры тирәләрендә Англиянең 10.191 тонна авырлыгындагы „Гретафилд“ танкерының батырылганлыгын хәбәр итә. Танкер экипажының 28 кешесен балыкчылар траулеры коткарган.

БЕРЛИН, 14 февраль. Англиянең 290 тонна авырлыгындагы батырылган „Тоджимо“ траулеры командасының 11 кешесе Ирландиянең көньяк-көнчыгыш ярына килеп чыкканнар. Англиянең көнчыгыш яры буенда Англиянең „Гарт“ пароходы сайга утырган. 9 кешелек команда коткарылган. (ТАСС).

БЕЛЬГИЯДӘ СОЛДАТЛАРНЫ СУДКА ТАРТУ

БЕРЛИН, 14 февраль. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Антверпенның хәрби суды 8 солдатның эшен тикшергән. Алар хезмәт итүдән баш тарткан булганнар һәм революцион җырлар җырлап Бург-Леопольд лагерыннан киткәннәр. Гаепләнүчеләрнең 7 сеһәр кайсы өчәр айга төрмәгә хөкем ителгән. Ике солдат хезмәт вактында үзләренең командирларына сызгырган өчен 8 көнгә төрмәгә хөкем ителгәннәр.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Кытай газеталарының хәбәр итүләренә караганда, Гуанси провинциясендә кытай гаскәрләре 13 нче февральдә чигенеп баручы япон частьләрен эзәрлекләүне дәвам иттергәннәр һәм кичкә таба Наньнин—Биньян—Умин шоссесендә күп кенә пунктларны алганнар. Кытайларның алгы частьләре 13 нче февральдә кич белән Наньнин бистәләренә килеп җиткәннәр. 14 нче февральдә монда зур сугышлар булган. Сентрал Ньюс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Наньнин секторында Шаньлин, Биньян һәм Умин тирәләрендә булган сугышларда японнарның 20 мең чамасы кешесе үтерелгән.

12 нче февральдә курчак хөкүмәт гаскәрләре отряды японнарның сугыш караблары ярдәме белән Фуцзянь провинциясенең көньяк-көнчыгыш ярында Дуншань атавына төшәргә маташкан. Кытайлар оборонасы ныклы каршылык күрсәткән. 14 нче февральдә атауда көн буена каты сугышлар барган.

Сентрал Ньюс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 1939 нчы елның 10 нчы февраленнән 1940 нчы елның 31 нче январена кадәр Хәйнань атавында 186 сугыш булган. Бу сугышларда японнарның 8.669 кешеләре үтерелгән. Японнарның 3 самолеты бәреп төшерелгән, 2 танклары, 3 катерлары, берничә орудиеләре һәм 20 бронеавтомобильләре ватылган. Бер орудие, берничә мең винтовка, күп санда пулеметлар һәм күп кенә башка төрле сугыш кирәк-яраклары кулга төшерелгән.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Хубэй провинциясенең үзәк өлешендә японнарның Цзиншаньнан төньяkка таба һөҗүм итүләрен кытайлар кире каккannнар. Кытай частьләре берничә пунктны алганнар.

Кытайларның артиллериясе Янцзы елгасында япон корабларына атуларында дәвам итәләр. 12 нче февральдә Аньхуэй провинциясендә Дунлю тирәсендә ату нәтиҗәсендә японнарның берничә транспортына зарар килгән. Шул ук көнне Фаньчан районында кытайлар артиллериясе японнарның гаскәрләр ташучы 4 транспортына аткан. Аларның икесе янган һәм баткан.

„Шэньчжоужибао“ газетасының хәбәр итүенә караганда, 13 нче февральдә Цзянси провинциясенең төньяк өлешендә Пынцзэдән ерак түгел бер урында кытайларның артиллериядән атулары нәтиҗәсендә японнарның зур сугыш транспорты баткан. Транспорт бортында японнарның 2 меңнән артык солдаты һәм офицеры, шулай ук 260 тонна чамасы сугыш йөкләре булган.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Суйюань провинциясенең көньбатыш өлешендә япон гаскәрләре тарафыннан алып барыла торган һөҗүмнең темпы соңгы көннәрдә шактый кимегән. Кытай гаскәрләре Баотоуга һәм Гуйхуага уңышлы һөҗүм башлаганнар.

„Синьбао“газетасы, 6 нчы февральдә кытай партизаннары японнарның Тайюаньдәге (Шаньси провинциясе) аэродромына кӧтелмәгәндә һөҗүм ясаганнар дип хәбәр итә. Нәтиҗәдә берничә самолет юкка чыгарылган. Япон сакчылыгыннан берничә йөз солдат үтерелгән һәм яраланган.

15 февраль. (ТАСС).

ҺАВА ҺӨҖҮМЕННӘН САКЛАНУ БУЕНЧА ЧУНЦИН ВЛАСТЬЛАРЫНЫҢ ЧАРАЛАРЫ

ЧУНЦИН, 15 февраль. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, яз якынлашу уңае белән Чунцин властьлары япон авиациясенең Чунцинга һөҗүм ясау ихтималына каршы кисәтү чаралары күрәләр. Үзәк районнардан күчерелә торган халык өчен шәһәр тирәләрендә качу урыннары төзүгә Чан Кай-ши приказы буенча 250 мең юань (кытай доллары) күләмендә акча җибәрелә. Мондый качу урыннарын төзү ике айда тәмам булыр дип уйлыйлар. Шул ук вакытта Чунцин властьларының һәм оборона штабының халыкны Чунцинның үзәк районнарыннан мәҗбүри рәвештә күчерә башлаганлыклары әйтелә.

ХРОНИКА

Ригада халыкара коньки ярышлары булды. Ярышта Латвиядән 10 һәм башка илләрдән 10 кеше катнашты. 500 метрга шуууда беренче урынны Уоллес (АКШ) алды. Аның вакты—43,8 секунд. 4 дестанция буенча булган очколар саны ягыннан беренче урынга Гаральсен (Норвегия) һәм Берзиньш (Латвия) чыктылар.

Домей Цусин агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Делидә (Һиндстан) 15 нче январьда өзелгән Япония—Һиндстан арасында сәүдә сөйләшүләре янартылган. Агентлыкның фикеренчә, бу сөйләшүләр договор төзү белән тәмам булачак, чөнки Европада сугышның киңәюе ике делегациянең дә карашын үзгәртте.

Фин ак гвардеецларына каршы сугышларда катнашучы—Советлар Союзы Герое кече лейтенант П. В. Усов.

М. Редкин фотосы (ТАСС фотохроникасы).

Литва республикасының 22 еллыгы уңае белән М. И. КАЛИНИН һәм В. М. МОЛОТОВ иптәшләрнең котлаулары

Литва республикасы төзелүгә 22 ел тулу уңае белән ССР Союзы Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш М. И. Калинин Литва республикасы президенты А. Сметона әфәндегә котлау телеграммасы җибәрде.

Шул ук вакытта Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш В. И. Молотов Литваның чит ил эшләре министре Ю. Урбшис әфәндегә котлау телеграммасы җибәрде.

ЛИТВА РЕСПУБЛИКАСЫ БӘЙСЕЗЛЕГЕНЕҢ 22 ЕЛЛЫГЫ

16 нчы февральдә Литва республикасы үзенең бәйсез яши башлавының 22 еллыгын билгеләп үтте. Балтык буендагы күп кенә башка илләр кебек үк, Бөек Октябрь Социалистик Революциясенең җиңүе нәтиҗәсендә, Литва да үзенә милли һәм дәүләт бәйсезлеге алды.

Литва дәүләте Версаль договорын оештыручыларның—Англиянең һәм Франциянең каршы килүләренә карамастан төзелде. Литва халкы поляк басып алучыларына һәм аларны яклаучыларга—Англия—Франция империалистларына каршы тигезсез көрәштә үзенең бәйсезлеген саклап калды. 1920 нче елны Совет хөкүмәте Литва республикасын беренче булып таныды һәм аңа ярдәм кулын сузды. 1920 нче елның 12 нче июлендә РСФСР белән Литва арасында татулык договоры төзелде. Бу договор буенча элекке Вильно губернасының шактый өлеше һәм Литва конституциясе белән дәүләтнең башкаласы дип танылган Вильно шәһәре Литва составына кертелде.

Англия—Франция империалистлары котыргысы белән паннар Польшасы Литвага карата күп тапкырлар басып алу омтылышларын күрсәтте. 1920 нче елның сентябрендә кызыл гаскәрләр Вильнодан киткәннән соң Литва хөкүмәте демаркация линиясе билгеләү һәм сугыш хәрәкәтләрен туктату турында Сувалкида 7 нче октябрьдә Польша белән килешү төзеде. Вильно өлкәсе Литвада калырга тиеш иде. Ләкин икенче көнне үк поляк генералы Желиговский бандалары Вильно өлкәсе территориясенә басып керделәр һәм Литва дәүләте җирен, шул исәптән Литва халкының борынгы башкаласы Вильноны басып алдылар.

Англия һәм Франция поляк сугыш чукмарларының бу ачыктан-ачык талауларын расладылар. Ул вакытта бары тик Совет хөкүмәте генә кискен протест белдерде һәм Вильноны Польша шәһәре дип бер вакытта да санамаганлыгын белдерде.

Литва республикасы төзелгән вакыттан бирле Советлар Союзы бу яш дәүләтнең суверенный хокукларын, бәйсезлеген һәм куркынычсызлыгын яклап килде.

Яшәргә сәләтсез булган Польша дәүләтенең җимерелүе яңа хәл тудырды. Батыр Кызыл Армия поляк паннары изүе астындагы халыкларны азат итте, украиналыларны, белорусларны, литвалыларны азат итте. Шулай ук Кызыл Армия моннан 20 ел элек поляк генераллары тарафыннан басып алынган Вильно шәһәренә дә азатлык китерде.

Польша дәүләте җимерелгәннән соң СССР чикләренә һәм Литвага куркынычсызлыкны тәэмин итү бурычлары килеп басты. СССР белән Литва арасында үзара ярдәмләшү турында төзелгән пактта бу бурычлар ачык һәм конкрет төстә чагылдылар. Вильно шәһәрен һәм Вильно өлкәсен Литва республикасына бирү турында һәм Советлар Союзы белән Литва арасында үзара ярдәмләшү турында 1939 нчы елның 10 нчы октябрендә кул куелган договор ике халык арасында тарихи яктан үскән дуслыкның йомгагы булды.

Литва халкы Советлар Союзының тынычлык сөю политикасын тирән симпатия һәм шатлык белән каршы алды. Үзенең бәйсез яшәвенең 22 еллыгын бәйрәм иткәндә Литва халкы үзенең тарихи язмышының Советлар Союзы белән яхшы күршеләрчә дуслык мөнәсәбәтләрен үстерүгә һәм ныгытуга нык бәйләнгәнлеген ачык күрә. СССР Балтык буе илләрен сугыш куркынычыннан коткарды. Англия—Франция сугыш блогы исә аларны сугыш куркынычына тартырга маташа иде һәм алардан СССР га каршы плацдарм сыйфатында файдаланырга омтыла иде.

СССР тарафыннан үткәрелә торган һәм үзара ярдәмләшү турында Совет—Литва договорында ачык чагылган эзлекле тынычлык политикасы Литвага экономик һәм культура ягыннан тагын да үсү өчен киң мөмкинлекләр бирде. СССР белән Литва арасында төзелгән тарихи договор Литва халкының үзенең киләчәгенә ышанычын ныгыта.

Партоешмаларда отчет-сайлау җыелышлары зур активлык белән бара

РЕЗЕРВ БЕЛӘН ЭШЛӘҮНЕ КӨЧӘЙТЕРГӘ

Почтамт партия оешмасы ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын тормышка ашыру өстендә эшләп, отчет чоры эчендә сизелерлек уңышларга ирешкән. Производствода партия членнарының авангардлыгын күтәрү, хуҗалык эшләренә партия контролен көчәйтү буенча байтак чаралар күрелгән. Коммунистларның политик һәм производство активлыклары күтәрелә бара.

Шулай да оешманың эшен бүгенге көннең таләпләренә тулысынча җавап бирерлек итеп кую өчен күп эшләргә кирәк әле. Барыннан да элек, партоешмада һәм, гомумән, работниклар арасында политик тәрбия эшенең куелышы начар булуын күрсәтергә кирәк. Партия оешмасы бу эш белән җитәрлек шөгыльләнмәгән. Коллективта эшләүче 554 кешенең 282 се социалистик ярыш белән чолганып алынмавы һәм стахановчылар саны аз булу моны бик ачык күрсәтә. Работниклар арасында хезмәт дисциплинасы йомшак. Моны раслау өчен бер ел эчендә прогул ясаган һәм хезмәт дисциплинасын бозган 243 кешенең эштән чыгарылу фактын күрсәтү дә җитә.

Оешманың үсеше канәгатьләнерлек түгел. XVIII нче съездан соң партиягә бары 10 кеше кабул ителгән. Кандидат итеп кабул ителгәннәр арасында комсомолецлар бары 3 кенә, ә биредә комсомолецлар саны гына да 60 ка җитә бит! Отчет-сайлау җыелышында фикер алышуларда катнашучылардан Зарипов, Потапов һ. б. иптәшләр оешма секретаре Романов һәм аның урынбасары Софраницкий иптәшләрнең бу мәсьәлә буенча йомшак эшләүләрен бик урынлы тәнкыйтьләделәр.

— Партия сафларына кабул итәргә лаеклы алдынгы иптәшләр бездә күп, тик алар белән эшләү җитәрлек булмады, — ди чыгып сөйләүче иптәш Зарипов. — Без аларны өйрәнергә, партиягә керергә хәзерләнү өчен аларга булышлыкны барлык чаралар белән көчәйтергә тиешбез.

Җыелышта чыгып сөйләүче иптәшләр партия членлыгына кандидатлар белән эшнең йомшак булуын аеруча күрсәттеләр. Дөрес, кандидатларның барсына да партпоручениеләр бирелгән. Ләкин еш кына хәлләрдә бирелгән поручениеләрнең үтәлеше тикшерелми кала. Иптәш Бикмурзинага агитация эше алып бару тапшырылган булган. Ләкин ул моны тулы үтәмәгән. Ә партоешма секретарьлары аның бу эшне ни өчен үтәмәве белән бөтенләй кызыксынмаганнар. ВКП(б) членлыгына 1932 нче елдан бирле кандидат иптәш Мостафинаны членлыкка күчерү турында партия оешмасы кайгыртмаган.

Биредә ВКП(б) ның Бауман райкомы турында да әйтми үтеп булмый. Почтамт партоешмасы секретаре иптәш Романов яш коммунист. Ул партия оешмасында җитәкче эштә беренче тапкыр эшли. Райком аның көндәлек эшенә аеруча нык булышлык күрсәтергә, оператив җитәкчелек итәргә тиеш иде. Ләкин райком тарафыннан җитәкчелек җитәрлек түгел. 5 айдан бирле монда райкомнан берәү дә булмаган.

Җыелыш коммунистларның үз оешмаларының эшен җидди тикшерү һәм каты тәнкыйть астына алу билгесе астында үтте. Партоешманың эше канәгатьләнерлек дип табылды. Яңа секретарь итеп җыелыш иптәш Романовны, аның урынбасары итеп иптәш Мәүлюдованы сайлады. ВКП(б) ның Бауман район конференциясенә делегат итеп иптәш Романов сайланды.

М. Хәмидуллин.

15—16 нчы февральдә Казан Энергокомбинат партоешмасында отчет-сайлау җыелышы булды. РӘСЕМДӘ: Коммунистлар партбюро секретаре иптәш Евлампиевның отчет докладын тыңлыйлар. И. Галиев фотосы.

КАНДИДАТУРАЛАР НЫКЛАП ТИКШЕРЕЛДЕ

Энергокомбинат партоешмасында отчет-сайлау җыелышының икенче көнендә доклад буенча карар кабул итү, партбюроның яңа составын һәм район конференциясенә делегатлар сайлаулар булды. Коммунистлар партоешманың отчет чорындагы эшенә бәя бирү һәм карар кабул итү мәсьәләсенә җидди карадылар. Партоешманың бу отчет чорындагы эше канәгатьләнмәслек дип табылды.

Партбюро бу чорда күп кенә төп мәсьәләләргә—партпропаганда эшенә, түбәнге матбугат эшенә, кандидатларны большевистик тәрбияләү эшенә, моссовый оборона эшләрен оештыруга, социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәтен җәелдерүгә, производствода хезмәт дисциплинасын ныгытуга җитәрлек игътибар бирмәгән. Җыелыш үзенең карарында ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын тулы һәм төгәл үтәүне тәэмин итү өчен партбюроның яңа составы партия эшенең төп тармакларына көндәлек игътибар бирергә һәм бу эшләр белән системалы рәвештә шөгыльләнергә тиешлекне аеруча күрсәтеп үтте һәм практик чаралар билгеләде.

Партбюроның яңа составына членнар һәм район конференциясенә делегатлар сайлау өчен кандидатуралар күрсәтү һәм аларны персональ рәвештә тикшерү актив рәвештә барды. Төп игътибар—җитәкче парторганнарга күрсәтелүче кандидатураларның практик эштә үзләрен ничек күрсәтүләренә, политик һәм эшлеклелек сыйфатларына бирелде.

Партбюро составына 7 член, район партконференциясенә тавыш бирү хокукы белән 6 һәм киңәш бирү хокукы белән бер делегат сайланды.

У. Ахметов.

УКЫТУЧЫЛАРНЫҢ БЕЛЕМЕН КҮТӘРҮ ИНСТИТУТЫНДА

Укытучылар белемен күтәрү институты партия оешмасы алдында коммунистларның һәм, гомумән, институтның фәнни кадрларының политик һәм теоретик белемнәрен туктаусыз күтәрү, фәнни эшләрнең сыйфатын күтәрү, мәктәпләрдә укыту һәм тәрбия эшләрен яхшыртуда укытучыларга ярдәм итү бурычлары тора.

15 нче февральдә, партоешманың отчет-сайлау җыелышында, оешма секретаре иптәш Семенов үзенең докладын әнә шушы алда торган бурычлардан башлады. Бу партоешма, моннан 8—9 ай гына элек оештырылуына да карамастан, үз алдында торган бурычларны үтәү йөзеннән шактый эш үткәргән. Коммунистлар үзләренә тапшырылган партпоручениеләрне намус белән үтәп киләләр. Оешма шушы кыска гына вакыт эчендә 5 кешедән 10 кешегә үсә.

Коммунистларның идея-политик белем дәрәҗәләрен күтәрү буенча да партия оешмасы аз эшләмәгән. Оешмада 9 кеше „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н үзләгеннән өйрәнә, бер кеше түгәрәктә укый. Иптәш Семенов коммунистларның политик белемнәрен күтәрү өстендә ничек эшләүләре турында беседалар үткәрә. Бу мәсьәлә буенча үткәрелгән махсус җыелышларда коммунистлар актив катнашалар һәм партия тарихын ничек өйрәнүләре турында сөйлиләр. ВКП(б) тарихын өйрәнү буенча тәҗрибә уртаклашу җыелышлары партиясез иптәшләр белән дә үткәрелгән.

Ләкин оешманың практик эшендә җидди кимчелекләр дә бар әле. Партия җыелышлары тарафыннан кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшерү, институт алдында торган бурычларны тулысынча тормышка ашыру өчен көрәш юк дип әйтерлек.

Мәсәлән, партия оешмасының гомуми җыелышы институт работниклары арасында беседаларны системалы рәвештә үткәрү турында карар кабул итә һәм моны үтәүне кабинет мөдирләренә—коммунистларга йөкли. Моннан соң күп вакытлар үтә, ләкин карарның үтәлеше белән берәү дә кызыксынмый һәм бу җаваплы эштә үзгәреш күренми. Карарларның үтәлеше турында җыелышларда информация ясау эш практикасына кертелмәгән.

Партоешма һәм аның секретаре иптәш Семенов институт алдында торган хуҗалык һәм укыту мәсьәләләре белән тиешле дәрәҗәдә кызыксынмый. Институт шушы елның январь аенда, укытучыларның белемнәрен күтәрү буенча бер еллык курс оештырырга тиеш иде. Бу җидди мәсьәлә. Ләкин, кызганычка каршы, бу эш бөтенләй өзелү алдында тора. Курсны башлап җибәрү түгел, хәтта курста укырга теләп гариза язучы иптәшләрнең дә саны бик аз. Әгәр дә партия оешмасы үз вакытында кирәк ярдәмне күрсәткән булса, ул һич шиксез, уңышлы хәл ителгән булыр иде.

Институт үзенең бөтен эшендә укытучыларга таянырга тиеш. Алдынгы укытучыларның эш тәҗрибәләрен туплау, аларны укытучыларның киң массасына җиткерү һәм укытучылар арасында политик тәрбия эшләрен алып бару, шулай ук, канәгатьләнерлек түгел.

Докладчы иптәш Семенов булган җитешсезлекләрне санап чыгу белән генә чикләнде, ул аларның сәбәпләрен күрсәтмәде, аларга тулы анализ ясамады. Төп җитешсезлекләрнең сәбәбе нәрсәдә? Сәбәбе шунда: оешмадагы коммунистлар производствода авангардлык ролен уйнамыйлар. Иптәш Семенов җитәкчелегендәге тарих кабинеты күп мәсьәләләрдән артта кала. Фикер алышуларда катнашучы иптәш Александров бу турыда ачык әйтте.

Җыелыш моңа аеруча әһәмият бирде. Партоешманың яңа җитәкчесе алда торган бурычларны уңышлы хәл итү өчен, иң беренче чиратта, шушы кимчелекләрне тиз арада бетерүгә аеруча әһәмият бирергә тиеш.

Җыелыш зур активлык белән үтте. Коммунистлар фикер алышуда актив катнаштылар.

Җыелыш партоешманың секретаре итеп Семеновны, аның урынбасарлары итеп Шибаев (математика кабинеты мөдире), Юсупова (башлангыч мәктәпләр бүлегенең фәнни эшчесе) иптәшләрне сайлады.

Рим Баһау.

БУА РАЙОНЫНДА

15 нче февральдә Буа районының 3 башлангыч партоешмасында отчет-сайлау җыелышлары булды. Җыелышлар зур активлык белән үтте. Докладчылар партоешмаларның состав ягыннан шактый үсүе һәм коммунистларның идея ягыннан үсүләре турында сөйләделәр.

Буа шәһәр советы янындагы партоешма (секретаре иптәш Фәхертдинов) отчет чорында партия сафларына 5 кандидат һәм 2 член кабул итте. Яңа кабул ителгән иптәшләр үзләренең политик белемнәрен күтәрү буенча җидди эшкә керештеләр. Кандидатлардан Яшин һәм Платарев иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы" ның 4 нче бүлеген өйрәнәләр. Яш коммунистлардан 5 кеше җаваплы эшләргә күтәрелде.

Фикер алышуларда 8 кеше чыгыш ясады. Алар оешманың алдынгы хатын-кызларны партия сафларына тарту буенча җитәрлек дәрәҗәдә эш алып бармавын күрсәттеләр.

16 нчы февральдә 5 оешмада отчет-сайлау җыелышы булды.

(ТатТАСС).

Районнарда отчет-сайлау җыелышлары

НОРЛАТ

15 нче февральдә Норлат МТС ындагы партоешмада отчет-сайлау җыелышы булып үтте. Партоешманың эше турында җыелышта иптәш Зеленов доклад ясады.

Отчет чоры эчендә партия сафларына 14 кеше кабул ителгән. Барлык коммунистларга да поручениеләр бирелгән һәм аларның күбесе үзләренә тапшырылган эшне яхшы гына үтәп киләләр. Коммунистлар производствода авангардлык үрнәге күрсәтәләр. Мәсәлән, беренче бригаданың (бригадиры иптәш Хәмидуллин) барлык тракторчылары ремонт буенча көнлек эш нормаларын 200 процентка кадәр үтәп киләләр.

Ләкин партоешманың эшендә җитешсезлекләр күп әле. Барыннан да элек, социалистик ярышка оешманың начар җитәкчелек итүен әйтергә кирәк. Узган елны Мөрәле МТС ы белән төзелгән ярыш договорлары тикшерелмәгән. Быел бу МТС бер МТС белән дә ярышмый. Отрядларда ярыш договорлары формаль рәвештә генә төзелгәннәр. МТС эшчеләре арасында масса-тәрбия эшләренең торышы һич тә канәгатьләнерлек түгел.

Нәтиҗәдә, МТС та тракторларга ремонт ясау планы 50 процентка гына үтәлгән. Кадрлар сайлап алу һәм механизатор кадрлар хәзерләү буенча да җидди кимчелекләр бар. Хатын-кызлардан механизатор кадрлар хәзерләү планы бөтенләй өзелгән.

ОСО һәм МОПР оешмаларында бер төрле дә эш алып барылмый. Партоешмада учетта торучы күп кенә коммунистлар үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү өстендә начар эшлиләр. Кайбер коммунистлар партия тарихын өйрәнү эшенә бөтенләй керешмәгәннәр.

Җыелыш көчле тәнкыйть астында үтте. Фикер алышуларда барлык коммунистлар да катнаштылар һәм кыйммәтле тәкъдимнәр бирделәр.

Аннары партбюро составын һәм партиянең район конференциясенә делегатлар сайлау үткәрелде. Партбюроның ике члены начар эшләүләре өчен сайлаулар вактында төшеп калды. Бюроның яңа составына Зеленов, Жарков, Носков иптәшләр һәм ВКП(б) ның район конференциясенә 8 делегат сайланды.

Х. Хәлилев.

БИЕКТАУ

Биектау районында беренче отчет-сайлау җыелышы „12 лет Октября" колхозы партоешмасында булды.

Партоешма секретаре урынбасары иптәш Архипова доклады буенча фикер алышуларда барлык коммунистлар чыгыш ясадылар.

ВКП(б) члены иптәш Гуськова болай диде:

— „12 лет Октября" колхозы артта баручы колхоз булып тора. Бу хәл партия оешмасының политик эшне хуҗалык эшләре белән бәйләп алып бара белмәве нәтиҗәсендә туды. Кай вакытларда авыл хуҗалыгы мәсьәләләре партия җыелышында тикшерелсә дә, аларда кабул ителгән карарлар үтәлмәделәр.

Укытучы иптәш Дмитриева интеллигенция арасында политика-масса эшләре алып баруның җитәрлек булмавы турында сөйләде.

Җыелышка катнашучылар партоешманың элекке секретаре иптәш Васильевның эшен йомшак дип таптылар.

Партоешма секретаре итеп иптәш Архипова, секретарь урынбасары итеп иптәш Гуськова сайланды. (ТатТАСС).

ЮТАЗЫ

15 нче февральдә Ютазы районының Чәкән авыл советы янындагы башлангыч партоешма коммунистларының отчет-сайлау җыелышы булды.

Партоешма секретаре отчеты буенча 6 кеше чыгып сөйләде. Алар партоешманың эшендәге кимчелекләрне кискен рәвештә тәнкыйть иттеләр.

ВКП(б) членлыгына кандидат иптәш Глухов, партия оешмасының югары уныш өчен начар көрәшүе турында сөйләде. Буденный исемендәге колхозда кар тоту һәм тирес чыгару планнары үтәлми. Узган ел 76 колхозчы хезмәт көннәре минимумын тутырмаганнар.

Яшрен тавыш бирү тәртибендә җыелыш иптәш Кривовны секретарь итеп сайлады.

(ТатТАСС).

Фин ак гвардеецларына каршы сугышларның геройлары

АРТИЛЛЕРИСТ-РАЗВЕДЧИК

ИВАН ПРЯНИКОВ

Һәр кем окопларда, һәммәсе дә ракета кабынуын һәм атака башлануын минут саен көтеп торалар. Ә ракеталар һаман да юк. Сугыш башлану озакка сузылды.

Туңган күлнең яры буендагы кешеләр дә шул ук хәлне кичерделәр. Артиллеристларның команда пунктының тыгыз блиндажында батареяне инде берничә тапкыр чакырдылар; батарея дәшмәде һәм пехота атакага башлый алмый торды.

Ул көнне дошманның миналары аеруча еш шартладылар. Дошман артиллеристларның команда пунктына якын килә башлады, ул пехотаны артиллерия ярдәменнән мәхрум итәргә теләде. Блиндаждан башны күтәреп карарга мөмкин булмады. Пуляләр шул кадәр көчле выжылдый иде.

Пехота кыйммәтле вакытны ычкындырды, кем булса да блиндаждан чыгып, пуляләргә, миналарга каршы йөгерергә, батареягә таба барырга тиеш иде.

Менә каяндыр блиндаж төбеннән кечкенә фигура күтәрелде. Ул — разведчиклар отделениесе командиры Иван Пряников иде.

Бу, донесениеләр һәм приказлар алып, дошман бонҗрасыннан көненә берничә тапкыр үтеп чыга торган Пряников иде. Пряников барасы булгач, бөтенесе дә яхшы булачакны, һәр нәрсәнең тәртиптә булачагын һәр кем белә иде. Шулай да моның ничек болай үтә алуына һәр кем гаҗәпләнә иде. Тик Пряников үзе генә гаҗәпләнмәде.

— Пуля минем буйга туры килми,—диде ул, — миңа иелеп торасы да юк: пуля барыбер мине эләктерә алмас, баш өстеннән үтеп китәр.

Менә бүген дә вакыйгаләр беркадәр вакытка Пряников кулында булып чыкты. Ут ачарга хәзерләнгән орудиеләр дә, ак финнәрнең башына төшәргә тиеш булган уннарча авыр снарядлар да, атака башлануны көтеп, хәзер окопларда яткан кешеләр дә. Боларның барсына да Пряников ход бирергә тиеш иде. Әгәр ул батарея командирына барып җитә алса һәм аны пехота командиры белән бәйләсә, бөтен нәрсә рәтләнәчәк.

Ә хәзер Пряников үзе капитан каршында тора һәм шлемын төзәтеп, приказ көтә. Уң кулына тоткан штыклы винтовкасы аның үзеннән биегрәк иде.

Бу юлы Пряников барган юл аеруча читен булды. Хәзер инде Пряниковка үзенең буена ышанырга мөмкин түгел иде. Чөнки ак финнәрнең атулары бик көчле иде. Иелергә дә, җиргә ятып үрмәләргә дә, канау буйлап яшеренеп барырга да туры килде. Ләкин, нишлисең, приказ приказ инде. Тизрәк батарея командирын күрергә кирәк. Пряников шул турыда гына уйлады.

Канауда ул үзен бөтенләй яхшы хис итте. Канау тирән иде. Бу яхшы булды. Җирдән үрмәләп баруга вакыт әрәм итәргә кирәк булмады. Монда йөгерергә дә мөмкин булды. Ләкин канаудан чыккач та, миналар арасына килеп эләкте. Нәрсә эшләргә? Яңадан канауга борылып кайтыргамы? Юк, Пряниковның, приказны үтәмичә, бер вакытта да кире борылып кайтканы юк. Пряников алга таба йөгерде. Миналар һаман шартлыйлар иде. Ләкин Пряников аларны ишетмәде, ишетергә дә теләмәде, ул аларны күрмәде һәм күрергә дә теләмәде.

Менә күзәтү пункты күренде. Батарея командиры булырга тиешле окопта берәү дә юк иде. Окоп күмелгән. Батарея командиры үзенең урнын алмаштырган булса кирәк. Ләкин ул кая киткән, аны кайдан эзләргә?

Пряников бер окоптан икенчесенә үрмәләп барды, ул кечкенә өй күрде, аңа таба китте. Батарея командиры бәлки шундадыр, дип уйлады ул. Берничә адым калганда кечкенә өйнең түбәсенә мина килеп төште. „Ярый әле өйдә берәү дә юк",—диде Пряников һәм ераккарак үрмәләп китте. Ул командирны уйсулыкта очратты һәм приказны тапшырды. Хәзер инде командир кайчан ут ачарга кирәклекне белде һәм батареягә команда бирде. Пряниковка шунда калырга тәкъдим иттеләр. Аңа әйттеләр:

— Син приказны үтәдең бит, кире китү нәрсәгә кирәк? Анда хәзер берәү дә йөрми, хәзер анда йөрергә дә мөмкин түгел бит. Син үзең дә беләсең ич.

„Я, мин киттем"—дип әйтергә дә өлгермәде, Пряников күздән югалды.

Тагын шул ук кыен юл, ләкин хәзер күңеллерәк иде. Пряников гөрелдәгән тавышлар ишетте. Әйе, бу—безнекеләр. Ут ачтылар. Димәк, бөтен нәрсә тәртиптә, димәк, атака башланды,—диде ул.

Пряников тагын капитан каршында. Ул кыска гына доклад ясый:

— Сезнең приказыгыз үтәлде!

Шул минуттан сугыш кырында бөтен нәрсә үзгәрде. Орудиеләр ялкын чәчтеләр, орудиеләрне коручылар авыр снарядларны ташырга өлгерә алмыйлар иде. Окопларда ятып, атака башлау өчен ракеталар җибәрелүне түземсезлек белән көтүчеләр, хәзер сугыш дәрте белән янып, „ура", „алга" тавышлары астында дошманны кысрыкладылар. Бу көнне атака аеруча яхшы барды. Зур җиңүгә ирешелде.

⁂

Икенче көнне Пряников куе урман эчендә, биек нарад башында утыра иде. Яңа гына таң аткан иде. Пряников бинокльне күзеннән алмады.

— Иптәш лейтенант, иптәш лейтенант, алар монда, әнә шалаш, әнә икесе чыкты, әнә тагын берсе, о, алар никадәр!

Бер минуттан батарея шалашка ата башлады. Менә шалаш ялкынланып яна. Ак финнәр бәреп ташланалар, җиргә авалар. Шалаш торган урында ак финнәрнең үле гәүдәләре генә өелеп калган иде. Иртә белән артиллеристлар аткан урынга кичен пехотачылар барып җиттеләр.

⁂

Кичен артиллеристлар дошманны һәм үз снарядларының ярылуын күзәтеп торуны оештырдылар. Телефон аппараты белән бергә мөмкин кадәр алгарак үтеп барырга кирәк иде. Билгеле, Пряников та шунда булды. Кар өстеннән акрын гына барганда, көтелмәгәндә мина ярылды. Телефонист Печников яраланды.

— Печников янына үрмәләп барырга кирәк, иптәшне аннан алып чыгарга кирәк,—диде Пряников һәм алга йөгерде.

— Үрмәләп бар, йөгермә! дип кычкырдылар Пряниковка иптәшләре.

Ләкин ул инде берәүнең дә сүзен ишетмәде.

Ул, яраланган сугышчыдан:

— Син үрмәләп бара аласыңмы?—дип, шыпырт кына сорашты.

Ул яраланган иптәшен саклык белән генә сөйрәткечкә салды һәм аны ут астыннан алып чыкты.

Яраланган иптәшен санитарларга тапшырып, Пряников үз батареясе снарядларының шартлавын күзәтүне дәвам иттерде.

З. Хирен.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ АРТЕЛЕ УСТАВЫНА 5 ЕЛ

ҖИР ҮЗ ХУҖАЛАРЫ КУЛЫНА КҮЧКӘЧ

Патша Россиясендә крестьяннәрнең өчтән ике өлеше ярлы иде. Алпавытлар һәм соры корт кулаклар аларны төрлечә эксплоатацияләделәр. Барлык крестьян хуҗалыкларының 30 проценты атсыз, 34 проценты җир эшләү өчен, иген игү өчен инвентарьсыз, 15 проценты бөтенләй чәчүлексез булганлыгы да безгә билгеле.



Миллионнарча ярлылар ачтан үлмәс өчен киң Россиянең бер почмагыннан икенче почмагына эш эзләп, икмәк-тозлык табып булмасмы икән дип эзләнеп йөрергә мәҗбүр булалар иде. Ләкин алар кайда гына барсалар да „кара сакал“ артларыннан калмаган, шул ук кулак, алпавыт, буржуй тозагына эләктеләр.

Бөек Октябрь революциясенә кадәр безнең Олы Әтнә авылы крестьяннәренең тормышы да нак әнә шулай күнелсез һәм караңгы иде.

Миңа хәзер 76 яшь. Мин ул күңелсез көннәрне үз күзем белән күргән һәм тормыш авырлыгын үз җилкәм белән татыган элеккеге ярлыларның берсе. Казахстанда Овчинников дигән кулакта тоташтан 25 ел батрак булып тордым. Ә батракның хәле билгеле инде.

Бүген, авыл хуҗалыгы артеленең Сталин Уставы кабул ителүгә 5 ел тулган көнне әнә шул турыда, элеккеге караңгы тормыш турындагы, җирсезлек турындагы, ачлык турындагы үткәннәр ихтыярсыз искә төшәләр.

Безнең Олы Әтнәдә 700 гә якын ярлы, урта хәлле хуҗалык, 50 ләп кулак хуҗалык бар иде. Чәчүлек җирләренең иң яхшыларын һәм иң күп өлешен (3.099 десятинәнең 2.000 десятинәсен) шул 50 кулак биләп килде.

Авыр тормышка чыдый алмагач, крестьяннәр патшага каршы, кулакларга һәм алпавытларга каршы еш кына баш күтәреп чыгалар иде. 1900 нче елда безнең Олы Әтнәдә дә шундый бер күтәрелеш булуы минем хәтеремдә әле. Җир сорап патшага каршы булган бу күтәрелештә катнашкан Хәмитов Шакир, Хаманов Әюп һәм башка бик күп ярлыларны яткырып суктырдылар, 80 шәр камчы бирделәр. Хәмитов Садыйк, Гайнуллин Самикны каторгага җибәрделәр. Шул вакытта камчы белән суктырылган Фәхреттин иптәш Гыйззәтуллин исән әле.

Без, ярлылар һәм барлык хезмәт ияләре, тик бөек Октябрь революциясеннән соң гына бәхетле булдык, якты тормышка чыктык.

1929 нчы елда безнең Олы Әтнәдә дә колхоз төзелде. Дәүләт акты буенча 1935 нче елны безгә 3.900 гектар җир гомерлеккә беркетелде. Шуның 2.657 гектары сөрелә торган җирләр, 692 гектары болынлыклар һәм башкалар.

Авыл хуҗалыгы артеленең Сталин Уставы буенча эшли башлагач колхозыбыз һәр яктан һәм бик тизлек белән үсте. Колхозчылар хәзер культуралы таза тормышта яшиләр. Минем, элеккеге батракның хәзерге көндә һичбер нәрсәгә дә мохтаҗлыгым юк. Тамак тук, өс бөтен. Йорт яхшы. Терлек-туар да җитәрлек.

Колхозыбызның алга китүе иген уңышының күтәрелүендә аеруча ачык чагыла. Элекке заманда, безнең җирләребездән кулаклар файдаланганда, десятинәсеннән 30 пот, бик күп булса 40 пот уңыш алына иде, хәзер шул ук җирләр 150—200 пот чамасы уңыш бирәләр. Соңгы 3 елда колхозыбыз бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 13,2 центнер иген уңышы алды. Икенче бригада 1937 нче елны 8 гектар мәйданда арышның һәр гектарыннан уртача 198 пот, 1938 нче елны 10 нчы бригада бригадиры иптәш Гарипов 22 гектар мәйданда солының һәр гектарыннан уртача 133 пот, үткән елны 6 нчы бригада бригадиры иптәш Мусин 12 гектар мәйданда арышның һәр гектарыннан 24 центнер уңыш алдылар.

Җир үз хуҗалары кулына, халык кулына күчкәч әнә шулай үзгәрде ул. Бу нәрсә дигән сүз? Яхшылап эшләгәндә барлык мәйданда да әнә шундый уңыш алырга мөмкин дигән сүз. Без аны эшләрбез. Чөнки без үзебез өчен, кулаклар өчен түгел, бөек илебез өчен, колхоз строеның тагын да матуррак, гөрләп чәчәк атуы өчен эшлибез.

Яшәсен безне җирле иткән Совет хөкүмәте һәм Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) партиясе!

Яшәсен колхоз уставы һәм аны иҗад итүче бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин!

Гариф Маннапов.

ЗУР КӨЧ ЭШТӘ

1933 нче елны колхозчы ударникларның беренче Бөтенсоюз съездында сөйләгән речендә иптәш Сталин:

„Колхозларда хатын-кызлар зур көч... Безнең бурыч—колхозларда хатын-кызларны алгы сафка чыгарудан һәм бу көчне эшкә кушудан гыйбарәт“ диде.

Бу тарихи күрсәтмәдән, аталарча бирелгән якын киңәштән соң үткән елларда, бигрәк тә авыл хуҗалыгы артеленең Сталин Уставы кабул ителгәннән соң, колхоз строен алга җибәрүдә, аны ныгытуда чыннан да колхозларда хатын-кызларның зур көч булуын без практикада бик ачык күрдек.

Хатын-кызлар колхоздагы барлык эшләрдә дә актив катнашалар, күп кенә эшләрдә ирләрдән уздыралар.

Безнең Олы Әтнә авылы, Киров исемендәге колхозда хезмәткә яраклы кешеләрнең 47 процентын хатын-кызлар тәшкил итә.

Орлыкларны яровойлаштыру, агулау кебек аеруча осталык һәм җаваплылык таләп итә торган эшләрне отлично итеп үтәүче, норма буенча көнгә 500 көлтә урнына 1.000 көлтә бәйләүче Хәкимова Зәйнәп, Сиражиева Саимә, Шакирова Мөкәррәмә, Әсләмова Майсәрә кебек стахановчыларыбыз белән без мактана алабыз. Колхозыбызда болар шикелле алдынгылар бик күп һәм аларның саны туктаусыз үсеп тора. Колхозыбызның товарлыклы сөтчелек фермасында да җитәкче эштә эшләүче хатын-кызлар бар. Мәсәлән, Таифә иптәш Галимҗанова фермада бригадир булып эшли. Иптәш Галимҗанова бригадасында 56 савым сыер бар. Ул үткән елны шул сыерларның һәрберсеннән уртача 1.490 литр сөт савып алды.

Хисапчылык, секретарьлык эшендә эшләүчеләребез дә хатын-кызлар. Олы Әтнә авыл советында председатель булып эшләүче Зәкия иптәш Хәйруллина, ул элек колхозыбызда рядовой колхозчы булып эшләгән кеше.

Мин үзем кырчылык бригадиры булып эшлим. Мактанып әйтмим, бу эштә бары икенче ел гына әле эшләсәм дә, ирләрдән калышмыйм, ә кайбер эшләрдә аларны уздырам да. Яхшы эшләвем өчен халык мине хезмәт ияләре депутатларының Олы Әтнә авыл Советына депутат итеп сайлады. Бу ышанычны аклау өчен мин бөтен көчемне биреп, тырышып эшлим һәм эшләрмен. Чөнки безнең илебездә, социализм илендә халык интересы өчен эшләүдән дә мактаулырак эш юк.

Безнең колхозыбызда хатын-кызлар өчен барлык уңайлы эш шартлары булдырылган. Бик күпләргә үрнәк булырлык даими яслебез бар. Балалар өчен даими эшләүче площадка да бар. Бу хәл балалы хатыннарга да колхоз эшендә якыннан торып катнашырга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, елына тик бөртекләтә генә 60 центнерга якын доход алучы Фазылянова кебек стахановчыларыбыз бар.

Авыл хуҗалыгы артеленең Сталин Уставы кабул ителүгә 5 ел тулу уңае белән без исәпләп карадык. Бик кызыклы сан килеп чыкты. 1938 нче елда колхозыбыздагы барлык эшнең 44,8 проценты хатын-кызлар тарафыннан башкарылган булып чыкты.

Шулай, зур көч зур эшләр башкара.

Разия Галимова.

Колхоз хата-лабораториясендә (Сталинград өлкәсе, Хоперский районы, „12-я годовщина Октября“ колхозы) чәчүлек орлык тикшерү вакты. Сулдан уңга: хата-лаборатория мөдире П. Г. Миронов һәм йөзпотчылар хәрәкәте инициаторларыннан А. Я. Гуров һәм Г. И. Козленков иптәшләр.

Маклецев фотосы. (ТАСС фотохроникасы).

СТАЛИН УСТАВЫН КАБУЛ ИТКӘННӘН СОҢ



Җәмагат терлекчелеген үстерү—колхозларны экономик яктан ныгытуда, колхозчыларны культуралы таза тормышлы кешеләргә әйләндерүдә көчле чараларның берсе булды һәм булып тора. Шуңа күрә дә җәмагат терлекчелегенә, гомумән терлекчелеккә партиябез, хөкүмәтебез һәм турыдан-туры иптәш Сталин үзе җидди игтибар бирәләр.

Авыл хуҗалыгы артеленең Үрнәк Уставында да бу мәсьәләгә зур урын бирелгән.

Уставның 4 нче статьясендә түбәндәгечә язылган:

„Артель, берничә төрле терлекләрдән торган катнаш терлекчелек товар фермасы яки терлекләрнең саннары күп булган вакытта специальләштырылган берничә терлекчелек товар фермалары оештыра“.

Бүген, авыл хуҗалыгы артеленең Сталин Уставы буенча эшләүгә 5 ел тулган көнне безнең Әтнә районы, Олы Әтнә авылы, Киров исемендәге колхоз уставның бу пунктын тормышка ашыру буенча нәрсәләр эшләде соң? Эшләнгән эш бар, ирешелгән уңышлар, һич шиксез, зурлар. Ә ул уңышларны киләчәктә тагын да зурайту өчен мөмкинлекләр чиксез күп. Чөнки колхоз строеның үзенчәлеге шундый аның. Ул туктаусыз үсә һәм үсәчәк.

Хәзер берничә конкрет сан. Сталин Уставы кабул ителү алдыннан (1935 нче елның 1 нче январена) безнең колхозның товарлыклы-сөтчелек фермасында барлыгы 142 баш нәселсез терлек һәм 4 баш метис (холмогор), товарлыклы дуңгыз фермасында барлыгы 20 баш дуңгыз бар иде. Ә хәзерге көндә товарлыклы-сөтчелек фермасында 366 баш терлек (80 проценты метислар), дуңгыз асрау фермасында 338 баш (барлыгы да метислар) дуңгыз бар.

Товарлыклы-сөтчелек фермасында саф холмогор токымыннан 12 үгез һәм үзебездә җитешкән саф холмогор токымлы 13 сыер, дуңгыз асрау фермасында саф канлы токымнан 4 баш дуңгыз бар.

Үткән елны сарык һәм ат фермалары оештыра башладык. Хәзерге көндә сарык фермасында 105 баш терлек бар. Ат фермасы өчен „Барабансон“ токымыннан 7 бия һәм бер айгыр сатып алдык. Шуның өстенә 12 баштан торган янут фермасы бар. Умартачылык та, акрын булса да үсеп бара. Анда хәзер 39 семья умарта бар.

Колхозчы хуҗалыкларын терлекле итү буенча да безнең фермаларыбызның зур урын тотуларын әйтергә кирәк. Тик соңгы ике елда гына да әле 40 колхозчы йорты ферманың булышлыгы белән сыерлы булдылар.

Товарлыклы-сөтчелек фермасы соңгы 3 елда һәрбер сыердан уртача 13 центнер сөт савып алды. Шул ук 3 елны терлекчелектән 110 мең сумнан артык доход алды.

Уставның 6 нчы статьясендә терлек азыгы җитештерүне киңәйтә бару, болын һәм көтүлекләрне яхшырта бару турында әйтелә. Бу эштә безгә хөкүмәтебезнең булышлыгы аеруча зур булды. Хөкүмәт безгә үз хисабыннан 400 гектарга якын мәйданда сазлык урыннарны киптереп бирде. Ул урыннарга элекке вакытта кереп тә булмый иде. Ә хәзер аннан печән чабып алабыз. Соңгы елларда 20 гектар мәйдан болынга төпләү үткәрдек. Кырга үлән һәм тамыр азык чәчүне елдан-ел киңәйтә барабыз. Силоска файдаланырлык үләннәрне бөтенесен дә силослыйбыз.

Кыскасы, безнең терлекчелек тармагы буенча Сталин Уставын тормышка ашыруның нәтиҗәләре әнә шундый. Без, әлбәттә, бу уңышлар белән чикләнмибез, терлекчелекне һәр яктан үстерү өчен хөкүмәтебез һәм партиябез тарафыннан, Сталин Уставы тарафыннан тудырылган барлык мөмкинлекләрдән тулысынча файдалануны оештырабыз.

М. Хәйруллин.

Әтнә районы, Киров исемендәге колхозның товарлыклы терлекчелек фермалары мөдире.

СТАЛИН ЭПОХАСЫНЫҢ БӨЕК ДОКУМЕНТЫ

(Авыл хуҗалыгы артеле уставының 5 еллыгына карата)

1935 нче елның 17 нче февраль көне—колхоз төзелеше тарихында данлыклы көн. Бу көнне СССР Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты колхозчы-ударникларның икенче Бөтенсоюз съездында авыл хуҗалыгы артеленең бер тавыштан кабул ителгән Үрнәк Уставын расладылар. Шул вакыттан башлап авыл хуҗалыгы артеле уставы дәүләт законы сыйфатында практикада кулланылып килә.

Халыкларның бөек юлбашчысы, колхозчы крестьяннәрнең сөекле дусты һәм остазы иптәш Сталин авыл хуҗалыгы артеленең Үрнәк Уставын эшләүдә турыдан-туры катнашты. Ул, уставны идея ягыннан рухландыручы һәм иҗад итүче булды.

Колхозчы крестьяннәргә оештыру ягыннан гаят зур көчкә ия булган бөек документ бирелде, социализм төзелешенең революцион теориясе һәм практикасы бердәмлеген бик яхшы төстә гәүдәләндергән документ бирелде.

Иптәш Сталин Уставка авылда яңа җәмгыять төзүнең иң югары, төп законы дип бәя бирде.

Авыл хуҗалыгы артеленең Сталин Уставы **колхозларда җәмагат интересларын шәхси интереслар белән кушу, шәхси интересларны җәмагат интересларына яраштыру** принципына нигезләнгән.

„Артель хәзерге шартларда колхоз хәрәкәтенең бердәнбер дөрес формасы...һәм бу тулысынча аңлашыла да: а) артель колхозчыларның шәхси, көнкүреш интересларын аларның җәмагат интересләры белән бергә дөрес итеп бәйли, б) артель шәхси интересларны һәм көнкүреш интересларын җәмагат интересларына уңышлы итеп яраштыра, шуның белән кичәге ялгыз хуҗалыкчыларны коллективизм рухында тәрбияләүне җиңеләйтә“ (Сталин. Ленинизм мәсьәләләре, бит 655).

Иптәш Сталин: авыл хуҗалыгы артеле,—ул, колхозларның җиңүен тәэмин итә торган форма дип күрсәтте.

Сталинчыл уставта **социализмның төп принциплары ачык язылганнар: җәмагат хуҗалыгында намус белән эшләү, эшче-крестьян дәүләте каршындагы йөкләмәләрне** төгәл үтәп аның интересларын саклау; доходларны хезмәткә карап бүлү; иҗтимагый социалистик милекне саклау һәм ныгыту.

Авыл хуҗалыгы артеленең Сталинчыл уставы колхозларны чын-чыннан большевистик, ә барлык колхозчыларны таза тормышлы итү өчен артель хуҗалыгын **ничек алып барырга** кирәклеккә өйрәтә.

Җир турындагы бүлек—уставның гаят әһәмиятле бүлеге. Колхозлар били торган җир артельгә сроксыз файдалануга, ягни **мәңгегә** беркетелде. Авыл хуҗалыгы артеле уставының бу положениесе Сталин Конституциясенә кертелде; шуның өстенә Конституциядә колхозлар җирдән **түләүсез** файдаланалар диелгән.

Җирне колхозларга мәңгегә беркетү—политик һәм экономик яктан гаять әһәмиятле акт. Җир тәртипләрен революцион юл белән үзгәртү өчен эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең күп еллык көрәшенә йомгак ясалды. Шуның белән бергә, колхоз җирләренең чиген бозу туктатылды, җирдән ныклы файдалану булдырылды һәм җирнең уңыш бирүен күтәрү мөмкинлегә тәэмин ителде.

Устав кабул ителүгә биш ел үтте. Бу—колхозларның чәчәк атуы, стахановчылык хәрәкәтенең үсүе, дисциплинаның һәм хезмәт җитештерүчәнлегенең күтәрелүе, күп миллионлы колхозчылар массасының таза тормышлылыгы үсү чоры булды. 1939 нчы елгы Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе бу җиңүләрне ачык күрсәтте.

Социалистик шәһәрнең авылга производство ягыннан системалы ярдәм күрсәтүе һәм җитәкче ролендә катнашуы аркасында, колхозчы крестьяннәр ялгыз хуҗалык белән чагыштырганда коллектив хуҗалык бирә торган өстенлекләрне тормышка ашырдылар. Ярлы һәм урта хәлле крестьяннәр, ялгыз хуҗалыкчылар булган вакытларында, 1926 нчы елны бары 466 миллион пот кына товарлыклы ашлык бирделәр. Ә 1938 нче елны шул ук крестьяннәр, колхозларга берләшеп, 1.980 миллион пот товарлыклы ашлык бирделәр.

Колхозларда хезмәт җитештерүчәнлеге ялгыз хуҗалыктагыга караганда күп тапкыр югарырак.

Икенче бишьеллык елларында колхозларның акча доходлары 4,6 миллиард сумнан 14,2 миллиард сумга кадәр, ягни 3 тапкырга артыграк үсте. Миллионер колхозлар саны елдан-ел үсә.

Колхоз терлекчелеге шактый үсте. Җирне эшләү һәм терлекләрне тәрбияләү яхшырды. Агротехниканың, зоотехниканың, механикалаштыруның аеруча алдынгы, фәнни алымнары колхозларда киң кулланыла. Хезмәтне оештыруда хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да күтәрү бурычларына тулы лаеклы булган звенолар системасы кертелә.

Колхоз тормышының Сталин Уставын тормышка ашыруга халык дошманнары котырынып каршылык күрсәттеләр. Алар уставның җирне колхозларга мәңгегә беркетү турындагы пунктын төрлечә бозарга һәм колхозларда җир төзү эшен өзәргә маташтылар; алар доходларны хезмәт көннәренә карап бүлүдән гыйбарәт булган социалистик принципны бозарга, колхозларда хезмәт дисциплинасын таркатырга, колхозларның җәмагат милкен урларга маташтылар.

Ләкин дошманнар исәпләрендә ялгыштылар! Аларның оялары тар-мар ителде. Ләкин кайбер җирләрдә фаш ителеп бетмәгән дошман элементлар әле колхозчыларның артта калган катлауларын артель уставын бозуга этәрергә маташалар. Намуслы колхозчылар моны онытмаска тиешләр!

Артельнең җәмагат хуҗалыгы—ул, иң әһәмиятлесе һәм хәл иткече. Артельдәге һәрбер членның төп бурычы—җәмагатьләштерелгән хуҗалыкта **намус** белән тырышып эшләү, колхозның артель формасы менә шушы принципка нигезләнә.

Артельдә колхозчы хуҗалыкларына кечерәк **шәхси хуҗалык** алып барырга да юл куела, ләкин ул җәмагатьләштерелгән хуҗалыкка карата **ярдәмче** сыйфатында гына булырга тиеш.

Шулай булуга да карамастан, 1939 нчы ел башында кайбер колхозчыларның үзләренең игтибарларын шәхси хуҗалыкны күпертүгә юнәлдерү вакыйгаләре беленде, хезмәтнең күп өлеше шәхси хуҗалыкка бирелә иде, ул төп доход чыганагы булып әверелдерелә иде, колхоз исә налог салынудан ышерену өчен генә файдаланыла иде. Шулай ук күп кенә колхозчы хуҗалыкларының шәхси файдалануларында устав буенча рөхсәт ителгәннән артыграк җир барлыгы да маглүм булды. СССР дагы барлык колхозларда колхозчы хуҗалыкларының шәхси файдалануларында булган артык җирләр бер миллион ярым гектардан артык иде.

Бу, урыннардагы партия һәм совет оешмаларының җитәкчеләре тарафыннан колхозларда авыл хуҗалыгы артеле уставының төп положениеләренең тормышка ничек ашырылуы тикшерелмәвеннән килеп чыкты, **барлык колхозчыларны социалистик рухта тәрбияләү** өчен системалы көрәш алып бармадылар. Тар-мар ителгән кулакларның калдыклары кайбер урыннарда монардан файдаланырга маташтылар, алар артта калган колхозчылар арасында буржуаз хосуси милекчелек тенденцияләрен күпертеләр.

ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының 1939 нчы ел 27 нче май карары колхоз төзелешендә партия политикасын бозуны кискен төстә бетерү программасын билгеләде.

Үз колхозының **җәмагат хуҗалыгында намус белән эшләүче** кеше генә колхозда тора ала. Хезмәткә яраклы һәрбер колхозчы өчен колхозда член булып тору хокукын бирә торган, маглүм күләмдә хезмәт көннәре минимумы билгеләнде.

Партия һәм совет органнарының бурычы—уставның төп положениеләренең тормышка ничек ашырылуын әледән-әле күзәтеп тору. Уставны бозучыларга карата административ тәртиптә чаралар күрергә кирәк. Ләкин иң әһәмиятлесе—колхозның җәмагат интереслары барыннан да өстенрәк булырга тиеш дигән социалистик принципны колхозчыларның бөтен массасының аңына җиткерү.

Колхозның җәмагат милкен ныгыту һәм арттыру гына продуктларның мул булуына һәм кешеләрнең культурасы үсүгә китерә. Һәрбер колхозчының шәхси хәле бары тик артель хуҗалыгының үсүе нәтиҗәсендә генә яхшырачак.

Безнең бурыч—**колхозларны ныгыту.** ВКП(б) ның XVIII нче съезды директивасы әнә шундый.

Колхоз төзелеше тәҗрибәсе кай вакытларда уставның теге яки бу параграфына аерым төзәтмәләр кертә. Колхозчыларның 1940 нчы елны булачак Бөтенсоюз съезды колхозларның үткән биш ел эчендәге гаят бай эш тәҗрибәләрен берләштерер. Бу тәҗрибәләрнең аеруча кыйммәтлеләре авыл хуҗалыгы артеле уставына кертеләчәк.

ВКП(б) ның XVIII нче съездында иптәш Сталин ясаган доклад бөтен җәмгыятебезнең үсү юлын, шул исәптән колхозларның үсү юлын да билгеләде.

Барлык резервлардан файдалану, хуҗалыкның социалистик системасында булган барлык мөмкинлекләрне ахрынача ачып салу, җәмагат милкен барлык чаралар белән үстерү, колхозчыларның бөтен массасының идея-политик дәрәҗәсен күтәрү,—совет крестьяннәре алдында торган бурычлар әнә шундый.

А. Уральский.

Фән һәм техника яңалыклары

Совет медицинасының яңа казанышлары

Москва хирургия җәмгыятенең соңгы утырышында совет медицинасының яңа уңышларын күрсәтә торган берничә кызыклы доклад ясалды.

Моннан өч ел элек профессор М. М. Невядомский (РСФСР Наркомздравының экспериментал онкология клиникасы) куркынычлы шешләрне дәвалауда нафталан эмульциясеннән файдаланырга тәкъдим иткән иде. Хирургия җәмгыяте утырышында доктор Б. Н. Берхина шушындый куркынычлы рак шешләре бик яман азган бер төркем кешеләр турында информация ясады. Кан тамырларына нафталан эмульциясе җибәрү аркасында аларның бер өлеше терелгән, калганнарының хәле шактый яхшырган.

Ашказаны туберкулезы—авыр һәм сирәк була торган авыру. Профессор А. Н. Рыжих шушы авыру белән озак еллар авыручы Б. фамилияле 57 яшьлек эшче турында сөйләде. Моннан бер ел элек үзәк рентгенология һәм радиология институты клиникасының хирургия бүлегендә аңа уңышлы операция ясалган. Операциядән соң Б. үзен яхшы хис иткән, авыруы тукталган.

СССР фәннәр академиясенең экспериментал биология институтының фәнни сотрудн иги А. Г. Лапчинскийның доклады зур кызыксыну тудырды. Утырышта катнашучыларга ул моннан берничә ай элек уң арт аягы киселеп аның урынына икенче бер күсенең сул аягы куелган күсене күрсәтте. Күчерелеп утыртылган аяк бик яхшы үскән һәм нормаль төстә эшкә ярый. Хәзер институт органнарны күчерү тәҗрибәләрен этләрдә дә сынарга уйлый.

Металл ленталар эшләүдә яңа метод

Металл ленталар гадәттә прокат юлы белән эшләнәләр. Мондый юл белән эшләнгән лентаның бәясе кыйммәт, ә сыйфаты еш кына түбән була.

„Металлхимзащита“ трестының Ленинград бүлеге лабораториясе начальнигы инженер Булах металл ленталар эшләүдә яңа метод тәкъдим итте. Электролитлы махсус ванна аркылы ток җибәрелә. Катод өстенә металл кисәкләре җыела һәм шулай итеп лента ясала.

Электропочта

Илебезнең уйлап табучылары Головацкий һәм Волков якын араларга корреспонденция тапшыру өчен электромагнит транспорт уйлап чыгарганнар. Аны алар электропочта дип атаганнар.

Электропочта магнит агымы көчләре белән эшли. Аның трубаларына соленоидлар куелган. Соленоид аркылы электр тогы үткәндә магнит агымы килеп чыга һәм ул тимер патронны трубага тартып, аны алга хәрәкәт иттерә. Инерция буенча патрон алдагы соленоидка кадәр бара һәм анда яңадан алга таба этелә.

Электропочта патронының хәрәкәт тизлеге—сәгатенә 150 километр, ә пневматик почтаның патроны сәгатенә 18—20 километр тизлек белән генә хәрәкәт итә.

Пневматикада кулланыла торган тоташ җиз трубалар урнына электропочтада трубалар кабель кәгазьдән ясала.

Фәнни-тикшеренү элемтә институты „Известия“ комбинатында һәм шәһәрләр ара үзәк телефон станциясендә электропочтасы төзүгә керешә. Электромагнитлы транспортер шулай ук Дзержинский исемендәге тимер юлның Люблино станциясендә дә төзелә.

АУЧЫЛАР ЯРЫШЫ

Казан аучылары Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы хөрмәтенә 24 нче февральдә ярыш үткәрәләр. Ярышта катнашу өчен Казанның спорт җәмгыятләре өчәр кешедән торган командалар билгеләделәр.

Ярышта катнашучылар чаңгыда 5 километр араны үтәчәкләр һәм финишка килеп җитәргә 25 метр калганда окопка граната ыргытачаклар. Шулай ук аучы мылтыкларыннан тарелкаларга атулар булачак.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӘМ ХӘРБИ ДИҢГЕЗ ФЛОТЫНЫҢ XXII ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

ВУЗЛАР ЯРЫШЫ

Казан шәһәренең ВУЗлары Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына багышлап ату спорты ярышлары үткәрделәр. Ярышларда ВУЗлардан 6 команда, елга техникумыннан бер команда катнашты.

Ярышучыларның һәрберсе яткан хәлдә 50 метрга 10-ар пуля, тезләнгән һәм баскан хәлдә 5-әр пуля атты. Казан Дәүләт Университеты командасы, мөмкин булган 1.000 очкодан 807 очко җыеп беренче урынны алды. Химия-Технология институты командасы икенче урынны (802 очко), Казан Авиация Институты командасы өченче урынны (801 очко) алдылар.

Узган елгы ярышларда Казан Авиация Институты командасы беренче урынны алып, күчмә кызыл байрак белән бүләкләнгән иде. Хәзер бу байрак Казан Дәүләт Университеты командасына бирелә.

Аерым атучылардан иптәш Гущин (Казан Дәүләт Университеты студенты), мөмкин булган 200 очкодан 180 очко, Коммуналь Төзелеш Инженерлары Институты студенты иптәш Бажанов 174 очко, Химия-Технология Институты студенты иптәш Золотов 173 очко җыйдылар.

ӘДӘБИ МОНТАЖ

Казанның 2 нче номерлы мәктәп укучылары Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына багышлап әдәби монтаж хәзерлиләр. Мәктәпнең драма түгәрәге монтажны хәзерләүдә зур дәрт белән эшли. Монтажга Татарстанның атказанган артисткасы иптәш Кадмина җитәкчелек итә.

Драмтүгәрәк иптәш Сталинның тууына 60 ел тулу юбилеенә багышлап та әдәби монтаж хәзерләгән иде. Яңа хәзерләнә торган әдәби монтажны башкаруда мәктәпнең җырчылары, декломаторлары, биючеләре һәм музыка коралларында уйнаучылары катнашалар.

Әдәби монтаж балаларның үзешчәнлек сәнгате смотрында катнашу программасына да кертеләчәк.

Хәрби диңгез клубында (Казан) производстводан аерылмыйча укучылардан бер төркем. РӘСЕМДӘ: укучылар инструктор Е. А. Успенский иптәшнең караблар төзелеше турындагы дәресен тыңлыйлар.

И. Галиев фотосы.

ПУЛЕМЕТЧЫЛАР ХӘЗЕРЛӘҮ

Осоавиахимның Казан Шәһәр Советы клубында пулеметчылар хәзерләү курслары ачылды. Курсантлар станоклы пулеметны һәм кул пулеметын өйрәнәләр. Шунда ук ату спорты буенча инструкторлар хәзерләү курслары да оештырылды. Курсларда укулар Беренче Май бәйрәменә тәмам булачак.

Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы уңае белән шул ук клубта снайперлар хәзерләү мәктәбе ачыла. Укучыларның 50 проценты допризывниклардан тупланачак.

ЯҢА ПРЕМЬЕРАЛАР

Яш Тамашачылар театры данлыклы еллыкка яңа премьера хәзерли. Театр укучы балаларга юбилей көннәрендә Островскийның „Бальзаминов“ исемле пьесасын күрсәтәчәк.

Премьера өчен яңа декорация һәм костюмнар хәзерләнә.

***

Татарстанның Курчак театры да бәйрәм көннәрендә үзенең постановкалары белән балаларга хезмәт күрсәтәчәк. Театр Шнейдер әкияте буенча эшләнгән „Бири-Баро“ дигән 4 пәрдәлек премьера хәзерли. Театрга шәһәрнең күп кенә мәктәпләреннән культура походлары оештыру турында заявкалар алынды.

КЫЗЫЛ АРМИЯ ТУРЫНДА ХУДОЖЕСТВО ӘДӘБИЯТЫ УКУЛАР ОЕШТЫРЫЛДЫ

Татпромсовет көтепханәсе Кызыл армиянең XXII еллыгына карата китап күргәзмәсе төзеде. Артельләрдә Кызыл Армия турында художество әдәбияты укулар оештырылды. Бу укуларны Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры һәм Зур Драма театры артистлары алып баралар. Алар Алексей Толстойның „Икмәк“, Фурмановның „Чапаев“ исемле әсәрләреннән өзекләрне укыдылар. Хәзер Кызыл Армиянең ак финнәргә каршы батырларча көрәшен күрсәткән сугыш эпизодлары турында укыйлар. Артель членнары художество әдәбияты укуларына зур кызыксыну белән йөриләр.

Госманов.

ӘЛМӘТ РАЙОНЫНДА

Осоавиахимның Әлмәт район советы, Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына багышлап, Әлмәт—Азнакай—Әлмәт маршруты белән 90 километрга чаңгы чабышы оештыра. 22—23 нче февральдә укучыларның оборона ярышлары үткәреләчәк. 10 нчы класс укучылары 10 километр дистанциядә чаңгы ярышы оештыралар.

„Марс“ колхозының Осоавиахим оешмасы „Осовиахим өе“ җиһазлады. Анда плакатлар, күргәзмә әсбаплар куелды. Биредә осоавиахимчылар противогазны һәм винтовканы өйрәнәләр.

Кызыл Армиянең җыр һәм биюләр ансамбле (Урта Азия Хәрби округының Н часте) чираттагы концертка хәзерләнә. Е. Халдей (ТАСС фото-клишесе).

Татар Дәүләт Опера театрында

„ИРЕК“ ПРЕМЬЕРАСЫ

Татар Дәүләт Опера театры сәхнәсендә икенче опера булып талантлы композитор, Татарстанның атказанган сәнгат эшлеклесе Нәҗип Җиһанов тарафыннан язылган (Сафин либреттосы) „Ирек“ операсы барачак.

„Ирек“ операсын сәхнәгә кую өчен Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театрының режиссеры иптәш Сарымсаков чакырылды. Опера Татарстанның атказанган сәнгат эшлеклесе иптәш Бергольц дирижерлыгында, художник иптәш Шипулин оформлениесендә куела.

„Ирек“ операсы февраль революциясе көннәрендә Казаннан ерак түгел татар авылларының берсендәге вакыйгаларне, ярлыларның һәм батракларның большевик Шамиль җитәкчелегендә алпавытка каршы көрәш алып баруын һәм авылда контрреволюция көчләренең җимерелүен, халыкның җиңү тантанасын күрсәтә.

4 пәрдә—7 картинадан торган бу операда театр коллективының төп иҗад көчләре катнашалар. Төп рольләрдән: Бибисара ролен—Татарстанның халык артисткасы Кайбицкая, Байрашова, Сакаева иптәшләр, Хәят ролен—Халитова, Зарова, Шамиль ролен—Артемов, Алиев, Сәлим ролен—Насреттинов, Сәйфеттинов, Мортаза ролен — Верниковский, Бичурин, Булат, Гариф ролен—Растовцев, Маннапов, Соколовский, Шаһвәли ролен—Маев, Пустоветов, Соловьев, Собхан ролен—Алмиев, Сәйфеттинев, Сәлимов, комиссар ролен — Пустоветов, Казанский, Ибрай ролен—Төхфәтуллин, Нурминский, мулла ролен—Әхмәдуллин, Алмиев һәм башка иптәшләр башкаралар.

Театр коллективы „Ирек“ операсы өстендә зур көч куеп тырышып эшләде. Операга барлыгы 80 гә якын репетиция ясалды. Театр бу яңа премьераны Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына хәзерләп өлгертә. 22 нче февральдә „Ирек“ операсына җәмагать смотры үткәрелә. Җәмагать каравына Кызыл Армия частьләреннән 600 гә якын кеше чакырылды.

Беренче постановка 24 нче февральдә булачак.

Р. Н.

КҮМЕР ЧЫГАРУ

Татарстанда төзү материаллары җитештерү промсоюзының Минзәлә районындагы „Заря Востока“ артеле Иске Тәкермән авылы янында ташкүмер чыгару эшенә керешә. Хәзергә кадәр 400 тонна күмер чыгарылды инде. Беренче чиратта 1.000 тонна күмер чыгарыла. Икенче чиратта 6.000 тонна күмер чыгарырга билгеләнде.

Татарстанда ташкүмер чыгару промышленность предприятиеләрен ягулык белән тәэмин итүдә зур файда китерәчәк.

ТАТАРСТАНДА ҖИЛ ДВИГАТЕЛЬЛӘРЕ

Татарстанда соңгы ике ел эчендә җил двигательләренең саны 73 кә җитте.

Әтнә районының Киров исемендәге колхозында, Әлки районының „Кызыл байрак“, Алексеевский районының „Красное Прикамье“ колхозларында җил двигательләре колхоз фермаларын һәм авыл халкын су белән тәэмин итү өчен файдаланылалар.

Быел Татарстанда 92 җил двигателе төзү планлаштырыла.

ТӨЗҮ МАТЕРИАЛЛАРЫ ҖИТЕШТЕРҮ

Татарстанның төзү материаллары җитештерү промсоюзы районнарда 17 артельне берләштерә. Алар кирпеч, известь, алебастр, черепица һәм башка төзү материаллары эшләп чыгаралар. Узган елны бу артельләр 4 миллион 851 мең сумлык төзү материаллары җитештергәннәр иде. 1940 нчы елда аларның эшләре шактый киңәя. Артельләр быел 6 миллион 700 мең сумлык төзү материаллары эшләп чыгарырга тиешләр.

Кама Тамагы районында алебастр эшли торган „Волжский Горняк“ заводы механикалаштырылды. Биектау һәм Югары Ослан районнарындагы известь заводлары газогенераторлы печьләр белән эшлиләр. Шуның аркасында известь җитештерү процесслары шактый киңәйде.

ХРОНИКА

— Тәкәнеш районының Лубъяндагы урман техникумында студентлар өчен ике катлы интернат төзүгә керешелде. Интернатны төзү Татарстан АССР ның 20 еллыгына тәмам булачак.

— 1939 нчы елны Кайбыч районының район үзәгенә ерак булган авыл советларыннан Хуҗа Хәсән, Олы Тәрбилде һәм Иске Бува авыл советлары телефонлаштырылды. Кайбычтан алып Мәлки авылына кадәр 27 километрга икенче чыбык сузылды.

— Сугышчан алласызлар союзының Апас район советы „Корбан бәйрәме һәм аның реакцион роле“, „диннең барлыкка килүе“ турында һәм башка темаларда дингә каршы күп кенә лекцияләр үткәрде. Һәрбер лекциядә 130 дан алып 200 гә якын колхозчы булды.

— Алексеевский районында политграмотаны өйрәнү буенча 27 түгәрәк оештырылды. Аларда авыл советлары башкарма комитетлары председательләре, колхоз председательләре, бригадирлар һәм ферма мөдирләре укыйлар.

— Апас районының Коллар авыл советы секретаре иптәш Вәлиев Икенче Бишьеллык (дүртенче ел чыгарылышы) заемы буенча соңгы 14 нче тиражда 25 сумлык облигациягә 750 сум акча отты.

ДҖОРДАНО БРУНО

(Яндырылып үтерелүенә 340 ел тулу уңае белән)

Моннан 340 ел элек, 1600 нче елның 17 нче февралендә, Рим шәһәрендәге Чәчәкләр мәйданында, атаклы галим һәм философ Джордано Бруно католик чиркәү руханилары тарафыннан тереләтә яндырылды. Католик чиркәвенең баш рухание Рим Папасы тарафыннан эшләнгән бу коточкыч вәхшилек—инквизиция акты—христиан диненең кушуы буенча һәм инҗил аятьләренә туры китереп эшләнгән иде.

Джордано Бруно 1548 нче елда, Италиянең Неаполь корольлыгында туган. Ул яшь чагында ук Доминикан ордены дигән монахлар берләшмәсенә керә, ләкин Брунонын яңа фикерле булуы, дингә начар каравы монахлар һәм руханилар арасында шик тудыра, аны эзәрлекләү башлана. Шунлыктан, ул монастырьдан Неапольгә аннары Женевага, Тулузага, Европаның башка шәһәрләренә китеп, Коперник тәглиматын һәм дөньяга яңача карашны таратып йөри. 1592 нче елда Италиягә кайткач, элек Венеция, аннары Рим инквизиторлары кулына төшеп, төрмәгә ябыла. Ләкин 7 ел төрмәдә утыру Брунонын какшатмый, ул үзенең фикереннән кайтмый, дөньяга карашын үзгәртми. Нәтиҗәдә, үлем җәзасына хөкем ителеп, терелэтә яндырыла.

XIV—XV нче гасырларда Европада сәүдә һәм промышленность капитализмының үсә, товар эшләп чыгару көннән-көн арта, беренче капитал туплау башлана, шулай итеп, реакцион феодализм җәмгыятенә алмашка буржуазия җәмгыяте килә. Яңа базарлар эзләп буржуазия диңгез юллары ача, Һиндстан һәм Кытай базарларын кулына төшерә. Яңа ачылган Американы үз колониясе итә. Боларның барсы да феодализм җәмгыятенең черен таралуын тизләтәләр.

Джордано Бруно, менә шушы чорда, табигать фәннәрен, бигрәк тә Коперник тәглиматына нигезләнгән яңа карашларны философик яктан исбат итеп, дөньяга яңача карашны теоретик яктан нигезләп чыга. Аның үткен уклары дини схоластикага, чиркәү хакимиятенә, фәхеш һәм эксплоатация оясы булган монастырьларга, Рим Папасына һәм, гомумән, попларга каршы юнәлдерелгән иде. Караңгылыкка тартучы попларның „тәглиматына“ каршы көрәшеп, Бруно фән һәм акыл көче белән табигатьне тикшергәндә генә хакыйкатькә ирешеп була, дигән фикерне куя.

Феодализм реакционерлары, чиркәү тарафдарлары, Рим Папасы, монахлар һәм поплар дөньяның төзелешенә мондый яңа карашның христиан диненә каршы килүен, әгәр ул тамыр җәйсә диннәргә һәм дин күләгәсендә рәхәт күреп яткан руханиларга, гомумән, эксплоататорларга каты удар булачагын аңладылар. Шунлыктан христиан дине руханилары бөтен көчләре белән Бруно тәглиматына һәм аны яклап чыгучыларга каршы рәхимсез көрәшкә чыктылар. Канлы инквизиция суды бу тәглиматка ышанган динсезләрне эзәрлекләргә һәм утка ягарга керешә. Ун меңнәрчә кешеләр „изге суд“ ның палачлары тарафыннан үтерелә. Инквизиция суды җирнең кояш тирәсендә әйләнүенә ышануы өчен атаклы галим Галилейне бу „гонаһ“ыннан тәүбә итәргә мәҗбүр итте. Философ Джордано Брунону һәм башка галимнәрне терелэтә яндырып үтерде.

Джордано Бруно җирнең һәм башка планеталарның кояш тирәсендә әйләнеше турындагы Коперник тәглиматын яклап чыкты гына түгел, ә бәлки бу тәглиматны, үзенең әсәрләрендә һәм чыгышларында тагын да үстерде, анардан яңа нәтиҗәләр чыгарды. Ул дөнья бушлыгы чиксез һәм андагы дөньяларның исәбе-хисабы юк, шуларның берсе булган кояш системасы чиксез бушлык эчендә бер утырау гына, ди. Кояш бөтен дөньяның үзәге түгел, бәлки кояш системасының гына үзәге, бушлыкта андый кояшлар бик күп, хәрәкәтсез төсле күренгән йолдызларның һәрберсе бер кояш. Анынча дөньяның чиге юк, шулай булгач, дөньяның теге ягында яши торган аллага да урын калмый. Шулай итеп, Бруно тәглиматы Тәүрат һәм инҗилнең дөнья төзелеше турындагы аятьләрен төбе-тамыры белән юкка чыгара.

Бруно фикеренчә, хакыйкат бер генә булып, аны эзләп табу диннәр эше түгел, бәлки фән һәм философия эше. Фән һәм философия белән диннәр арасында һичбер килешүнең булуы мөмкин түгел. Бруно философик, гыйлми мәсьәләләрне тикшергәндә элек аның дөреслегенә шикләнеп карый, аннары аны битараф рәвештә тикшерә, шулай ук, ул дингә һәм чиркәү руханилары авторитетына ышанмый, шикләнеп карый, фән һәм акыл ярдәме белән табигатьне өйрәнә.

Джордано Брунода материалистик тенденция бик көчле. Брунонын материалист һәм атеист булуын исбат итү өчен, аңа дошман булган реакционер динче „профессор“ Шредерның Брунога памятник салуга каршы Кельно шәһәрендә сөйләгән сүзләрен китерү дә җитә. Шредер: „Ул (ягни Бруно) алланың үзенә каршы чыкты, ул аның барлыгын һәм куәтен, фантастик рәвештә адашып инкар итте, ул үзенең әсәрләрендә иң тупас пантеизмны яклап чыкты. Бруно кем иде ул? Ул качкан монах, азган рухани, Гайсага һәм чиркәүгә каршы баш күтәрүче, алланы инкар итүче әхлаксыз бер кеше, тәхет белән михрап дошманы, кыскасы, чын мәгънәсе белән революционер иде“ ди. Шунсы характерлы: 1889 нчы елда салынган бу памятник күптән түгел генә җимерттерелде.

Россиядәге православный чиркәү дә дингә каршы чыгучыларны каты җәзалауда католик чиркәвеннән калышмады. Россиядәге һәрбер монастырьда җир асты төрмәсе бар иде, анда еретикларны ачка аптыратып, төтен белән тынчыктырып үтерәләр, стена эченә кертеп кирпеч белән томалап, сылап куялар, терелэтә яндыралар иде. 1735 нче елны, башкыртлар восстаниесенә катнашканлыгы өчен, башкырт Тайгилде патша палачлары тарафыннан авыр җәзага тартыла, ниһаять, камчы астында чукынырга мәҗбүр була. Ләкин ул, кире исламына кайтканлыгы өчен губернатор Татищевнең приказы буенча чукындырылган башкыртлар алдында терелэтә яндырып үтерелә.

Диннәр тарихында, мондый фактлар бик күп. Диннәр һәм аларның руханилары һәр вакыт искелекне яклап, һәрбер яңалыкка каршы көрәшеп, эксплоатация коралы һәм реакция таянычы булып килделәр.

Б. Халид.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛАР

Бәхетсезлеккә очрау. Шәһәр урамнарында еш кына шаярып йөрүче балаларны очратырга туры килә. Алар трамвай вагоннарына асылынып йөриләр, автомобильләргә тотынып чаңгыда һәм конькида шуалар. Нәтиҗәдә мондый балалар еш кына бәхетсезлеккә очрыйлар. Шушы көннәрдә ике прицепка тагылган трактор Татарстан урамыннан үтеп барган вакытта малайлар прицепкаларга тотынып уйнаганнар. 14 нче мәктәптә укучы 9 яшьлек А. Насыйбуллин прицепканың берсенә менеп утырган, ләкин төшәргә маташкан вакытта прицепка астына егылып төшеп, тапталып үлгән.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

„Трансэнергокадр“ның
Казан Автомәктәбе
производстводан аерып һәм аермыйча укытып
III нче класс шоферлар хәзерләү буенча
20 нче февральдән
КУРСЛАР АЧА
III нче класс шоферлардан II нче һәм I нче класс шоферлар хәзерләү курсларына укучылар алу дәвам итә.
Шоферлар хәзерләү һәм шоферларның квалификацияләрен күтәрү курсларына укучылар предприятиеләрдән бирелгән командировкалар белән генә алыналар.
III нче класс шоферлар хәзерләү курсларына хатын-кызлар командировкасыз да алыналар.
Казан, Банк урамы, 15. 314—2—1

КАЗМЕХКОМБИНАТНЫҢ
Н. К. Крупская исемендәге
ФЗУ МӘКТӘБЕ
мех әйберләре тегү буенча югары квалификацияле тегүчеләр хәзерләү өчен
УКУЧЫЛАР АЛА
УКУ СРОГЫ 1 ЕЛ.
Мәктәпкә 17—18 яштәге һәм 6—7 класс күләмендә белемле хатын-кызлар алыналар.
Гариза белән бергә, керүченең белеме һәм яше турында белешмәләр бирелергә тиеш.
Мәктәпкә алынганнарга, аларның академик һәм практик өлгерешләренә карап, айга 70 сумнан 130 сумга кадәр стипендия бирелә.
Күрсәтелгән документлар белән гариза җибәрү өчен адрес: Казан, Яңа бистә, Кече Ямашев урамы, 71. Телефон 44—14. 182—4—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
17 нче февральдә
КЫЮ КЫЗЛАР
Талон 117.
18 нче февральдә
көндез **БАНКРОТ** (талон 118)
кич **КҮЗЛӘР** (талон 119)
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 17 нче февральдә, шулай ук иртәгә көндез һәм кич
Бакчалар чәчәк ата
Талоннар: бүген 103. Иртәгә көндез 21, кич 104.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

КИРОВ РАЙОНЫНДАГЫ
КУЛЬТУРА САРАЕНДА
Яш Тамашачылар театры спектакльләре
Бүген, 17 нче февральдә, шулай ук 18 нче февральдә көндез һәм кич
СКАЗКА
Талоннар: бүген 53, иртәгә көндез 54 һәм 55, кич 56 һәм 57.
Спектакльләр бүген кич 9 сәгать 30 минутта, иртәгә көндез 12 сәгатьтә һәм кич 8 дә башлана.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн Москваның Ленин орденлы Дәүләт циркы артистларының
ГАСТРОЛЕ
СТРАТОС—3
Номерлар орденлы артист БАСТ җитәкчелегендә башкарыла. Аэропланда үлем әлмәкләре һәм башка күп номерлар.
РСФСР ның атказанган һәм орденлы артисты **М. ЗОЛЛО** гастрольләре дәвам итә.
18 нче февральдә зур программа буенча
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ
Уеннар көндез 12 дә, кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

Совет кинематографиясенең XX еллыгы уңае белән,
„ЧАТКЫ“ КИНО-ТЕАТРЫ
иң яхшы художестволы тавышсыз фильмнәр буенча
КИНОФЕСТИВАЛЬ
үткәрә.
17 һәм 18 нче февральдә „Кастусь Калиновский“ (1927 нче елда чыгарылган), 19 һәм 20 нче февральдә „Чыңгыз Хан нәселе“ (1928 нче елда чыгарылган), 21 һәм 22 нче февральдә „Иуда“ (1929 нчы елда чыгарылган) исемле тавышсыз фильмнәр күрсәтелә.
Сеансларда концерт оркестры уйный.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Яңа фильм **ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП**
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	**ДИҢГЕЗ ПОСТЫ** „СЕДОВЧЫ ГЕРОЙЛАРГА ДАН“ һәм „СОВЕТ СӘНГАТЫ“ киножурналлары күрсәтелә.
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	**МИНИН һәм ПОЖАРСКИЙ**
„Колхозник“ 4, 6, 8 һәм 10 да.	**Инженер Кочинның ялгышуы**
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9—30 да.	**КАСТУС КАЛИНОВСКИЙ**
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5-30, 7-10, 8-50, 10-30 да.	Көндезге һәм кичке сеансларда **ПАТРИОТ** Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	**СОҢГЫ ТӨН**
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	**УНБЕР БАШКАЛА**

„Динамо“ ның Татарстан Республика советына ТӘҖРИБӘЛЕ МАШИНИСТКА кирәк. Чернышевский урамы, 12/20 адресы буенча килергә, яисә 34—91 телефоны буенча шалтыратырга. 316—3—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР, № А — 247 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 644.